| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

18 декабря 2020г. с.Шалты № 10

Шалты авыл җирлегенең 2021 елга
һәм 2022, 2023 еллар план чорына
бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының “Шалты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының “Шалты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1 нче статья

1. 2021 елга Шалты авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Шалты авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 3265,7 мең сум;

2) Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 3265,7 мең сум;

3) Шалты авыл җирлеге бюджеты дефицитының гомуми күләме 0 мең сум.

2. 2022 һәм 2023 елларга Шалты авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Шалты авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2022 елда 3282,8 мең сум һәм 2023 елда 3303,9 мең сум;

2) Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2022 елда 3282,8 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 79,6 мең сум һәм 2023 елда 3303,9 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган

чыгымнар 159,9 мең сум;

3) Шалты авыл җирлеге бюджеты дефицитының гомуми күләме 2022 елда 0 мең сум һәм 2023 елда 0 мең сум.

3. 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 нче статья

1. 2022 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

2. 2023 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

3. 2023 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

3 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 нче статья

1. Шалты авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Шалты авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 нче статья

1. 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге

бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Шалты авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. 2021 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәү өчен Шалты авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 0 мең сум, 2022 елга 0 мең сум, 2023 елга 0 мең сум күләмендә расларга..

6 нчы статья

1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен раслау, 2021 елга авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итүне оештыру өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү буенча төзелгән килешүләр нигезендә Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен 1406,2 мең сум күләмендә, 2022 елга 1406,2 мең сум күләмендә, 2023 елга 1406,2 мең сум күләмендә.

2. 2021 елда Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7 нче статья

Баулы муниципаль районы бюджетыннан 2021 елда бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 1833,9 мең сум, 2022 елда-1850,0 мең сум, 2023 елда-1858,9 мең сум күләмендә дотацияләрне расларга.

8 нче статья

Шалты авыл җирлеге бюджетында Баулы муниципаль районы бюджетыннан хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу өчен җирлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне 2021 елда 99,8 мең сум, 2022 елда-100,8 мең сум, 2023 елда-105,0 мең сум, 2023 елда-105,0 мең сум дип расларга.

9 нчы статья

1. Җирле үзидарә органнары 2021 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

10 нчы статья

Шалты авыл җирлеге бюджеты акчаларының калган өлеше 2021 елның 1 гыйнварына Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2020 елда түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның кулланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2021 елда Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

11 нче статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Шалты авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

12 нче статья

1. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Фаткуллин З.Х.